Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 сентябрь, 2020 ел № 10

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Иске Кощаково авылында Кыр урамы буенча урта басымлы газүткәргече белән Болын урамындагы түбән басымлы газүткәргечен боҗралау (закольцовка)» линияле объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә,

2020 елның 24 августындагы гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Иске Кощаково авылында Кыр урамы буенча урта басымлы газүткәргече белән Болын урамындагы түбән басымлы газүткәргечен боҗралау (закольцовка)» линияле объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәсен исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Иске Кощаково авылында Кыр урамы буенча урта басымлы газүткәргече белән Болын урамындагы түбән басымлы газүткәргечен боҗралау (закольцовка)» линияле объекты территориясен планлаштыру проектын һәм аны ызанлау проектын электрон чыганакта, кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов